**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№242**
**18.01.2024**

Башкарма комитетның 2020 елның 25 декабрендәге 7326 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бүлү буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 25 декабрендәге 7326 номерлы Карары белән (2021 елның 3 декабрендәге 7864 номерлы, 2023 елның 20 июлендәге 6460 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бүлү буенча комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Г.Н. Сухованы комиссия составыннан чыгарырга;

2) Валгушева Гөлнара Илдус кызы – комиссия секретаре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсенең сәламәтлек саклау ресурслары белән оештыру-икътисадый идарә итү бүлеге башлыгын комиссия составына кертергә (килешү буенча).

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов